ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай
муниципальрайоны
муниципаль беремлеге
ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Старое Ильдеряково

Совет Староильдеряковского сельского поселения

Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603000718 БИК 049205805
КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП
Тел.: 4-47-30

# КАРАР

№ 26 27.05.2021 ел

## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 115 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 397 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 115 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 115 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 19 мартындагы 21 номерлы карары;

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru 5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе С.М. Маклаков